ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 6 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 өлештә «белемнең сыйфатын бәяләү» сүзләрен «белем сыйфатын бәяләү чаралары» сүзләренә алмаштырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ һәм $3^2$ өлешләр өстәргә:

«$3^1$. Мәгариф системасына мониторингны гамәлгә ашыру кысаларында үткәрелә торган белем сыйфатын бәяләү чараларына гомуми белем сыйфатын региональ, илкүләм һәм халыкара чагыштырма тикшеренүләр, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан исемлеге һәм үткәрү тәртибе билгеләнә торган (региональ чаралардан тыш) белем сыйфатын бәяләү буенча башка чаралар керә.

$3^2$. Гомуми белем сыйфатын региональ чагыштырма тикшеренүләр Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган органы карары буенча үткәрелә. Региональ чагыштырма тикшеренүләрнең исемлеге, федераль башкарма хакимиятнең мәгариф өлкәсендә тикшерү һәм күзәтчелек итү функцияләрен башкара торган органы белән килештереп, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган органы тарафыннан билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 14 июнь
№ 42-ТРЗ